МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

05.03.2014 № 102

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 26 мартында теркәлде, №2263

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында гражданнар дәүләти гражданлык вазыйфасына билгеләнгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында гражданнар дәүләти гражданлык вазыйфасына билгеләнгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының

керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында гражданнар дәүләти гражданлык вазыйфасына билгеләнгәндә һәм дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 28.02.2013 ел, №131 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2013 елның 21 мартында теркәлгән, №1841) үз көчен югалткан дип танырга.

**Министр** **А.Р.Шәфигуллин**

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
5 март, 2014 ел, №102
боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында гражданнар дәүләти гражданлык вазыйфасына билгеләнгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. “Җитәкчеләр” категориясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары:

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының эшләр идарәчесе;

Министрлык бүлеге начальнигы;

Министрлыкның муниципаль районлагы (шәһәр округы) территориаль органы җитәкчесе;

Министрлыкның бүлек начальнигы урынбасары;

сектор мөдире;

Министрлыкның муниципаль районлагы (шәһәр округы) территориаль органы җитәкчесе урынбасары.

2. “Ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасы – министр ярдәмчесе.

3.“Белгечләр” һәм “тәэмин итүче белгечләр” категорияләрендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары:

3.1. юридик бүлектә – вазыйфаи бурычларын үтәү контрольлек һәм күзәтчелек чараларын хәл итүне күздә тоткан әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.2. дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч;

3.3. мәгълүмати технологияләр, автоматлаштырылган системаларга техник хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану, мәгълүмати иминлекне тәэмин итү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.4. планлаштыру, финанслау һәм хезмәткә түләү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.5. контрольлек-ревизия эше бүлегендә - әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч, 1 разрядлы белгеч;

3.6. дәүләт сатып алулары бүлегендә - әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.7. социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.8. социаль регистрны формалаштыру бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче;

3.9. социаль ярдәм чараларына аудит бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.10. техник реабилитация чаралары һәм санаторий-курорт ялы белән тәэмин итү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.11. пенсиягә өстәмә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.12. социаль яктан якланылмаган категорияләр өчен эш урыннарын булдыру бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.13. хезмәт һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү базарына мониторинг бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.14. һөнәргә өйрәтү һәм профориентация бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче;

3.15. хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән берлектә эшләү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.16. чаралар үткәрүне оештыру бүлегендә - әйдәп баручы белгеч;

3.17. социаль хезмәт күрсәтү сыйфатына идарә итү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч-эксперт;

3.18. административ-хуҗалык бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.19. җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.20. мобилизацион эш һәм гражданнар оборонасы секторында - әйдәп баручы белгеч;

3.21. халык белән эшләү секторында - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант.

---